Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Иске Үзи авыл җирлеге башкарма
комитеты
423050, Татарстан Республикасы
Аксубай районы, Иске Үзи авылы,
Ленин ур., 2А нче йорт
т. 4-13-48

Исполнительный комитет
Староузеевского сельского поселения
Аксубаевского муниципального района
Республики Татарстан
423050, Республика Татарстан
Аксубаевский район с.Старое Узеево,
ул.Ленина, д.2А
т. 4-13-48

КАРАРЫ

№4 17 октябрь 2022 ел

" Аксубай муниципаль районының
Иске Үзи авыл җирлеге
Яңа Баланда авылында халык җыенын билгеләү
һәм гражданнарның үзара салым чараларын
кертү һәм файдалану турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районы «Иске Үзи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. 1. 2022 елның 26 октябрендә 11 сәгать 00 минутка түбәндәге адрес буенчаТатарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлегенең Яңа Баланда авылы Киров урамында үзара салым кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2023 елда Аксубай муниципаль районының Иске Үзи авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә; 1 төркем инвалидлардан, БВС ветераннарыннан һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Украинада катнашучы граңданнарның гаиләләреннән тыш; җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчалардан түбәндәге эшләрне башкаруга ризамы:

1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- авыл җирлегенең торак пунктлары чикләрендә урамнарны кышкы тәртиптә тоту (ягулык-майлау материаллары сатып алу);
- юл полотносын урнаштыру (грунт күтәрү, урамнарны ком һәм вак таш белән яңарту)
- щебень сатып алу;

2. Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итү Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру;
- Гагарин урамында кое бораулау

ӘЙЕ ЮК

3. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының Иске Үзи авыл җирлегенең информацион стендларында һәм Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән кабул ителгән көннән 10 көн эчендә игълан итәргә http://aksubaevo.tatar.ru.

Аксубай муниципаль районы
Иске Үзи авыл җирлеге башлыгы: Н.В.Айдова